Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлегенең
Иске Гришкино авылында гражданнар җыены

2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында

18.11.2024 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 8 ноябрендәге 12 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләре буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” карары нигезендә, Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино авылы гражданнар җыены

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2025 елда Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы тыл ветераннарыннан, 18 яшькә кадәр тәрбиядә балалары булган аз керемле күпбалалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

«1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Азин урамына 350 метр, Елге аръягы урамына 500 метр вак таш сатып алу һәм вак таш салу, зиратка кадәр юл, скважинага кадәр юл);

2) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Иске Гришкино торак пунктындагы скважиналарны ремонтлау).

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (үлән чабу, кышкы чорда юлларны кардан чистарту, зиратта агачларны йоклату, триммер сатып алу).»

2. Әлеге карарны Иске Гришкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында “Иске Гришкино авыл җирлеге” бүлегендә (http://mendeleevsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга

Халык җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы_______________ К.И.Алексеев
(имза) (имзаның аңлатмасы)